РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2021 с. Сарманово № 384

**«Урта яисә югары педагогик белем алган һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының муниципаль белем бирү оешмаларына педагогик хезмәткәрләр вазыйфасына эшкә алынган укуны тәмамлаучыларга бер тапкыр бирелә торган түләүләр билгеләү тәртибе һәм шартлары турында» нигезләмәне раслау турында**

Матди ярдәм күрсәтү, белем бирүне үстерү һәм район халкын сыйфатлы һәм һәркем файдалана алырлык белем бирү хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру максатларында, шулай ук белем бирү системасында яшь белгечләрне беркетү процентын арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. «Урта яисә югары педагогик белем алган һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының муниципаль белем бирү оешмаларына педагогик хезмәткәрләр вазыйфасына эшкә алынган укуны тәмамлаучыларга бер тапкыр бирелә торган түләүләр билгеләү тәртибе һәм шартлары турында» нигезләмәне расларга.
2. Сарман муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Сарман муниципаль районының муниципаль бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә финанс чаралары бүлеп бирүне исәпкә алырга.
3. Әлеге карарны ТР Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары И.Р. Сәхиповага йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе Ф. А.Вәлиев